Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Средняя общеобразовательная школа № 8 г.Нурлат Республики Татарстан»

«Рассмотрено» Руководитель ШМО _______ /Мазитова Л.К./ Протокол № 1 от«27» 08 2018г	«Согласовано» заместитель директора по УВР _______/Григорьева Г.Д./ «28» 08 2018г	«Утверждено» Директор МБОУ«СОШ№8 г.Нурлат» _______/Граф А.А./ Приказ № 253 от« 28 » 08 2018г

Рабочая программа
по предмету «Родная (татарская) литература»
для 11 класса
Сафиной Розы Идрисовны,
учителя высшей квалификационной категории

ПРИНЯТО
на заседании педагогического совета школы
Протокол № 1 от 29.08.2018г.

2018-2019 учебный год

Аңлатма язуы

Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелде:

-Россия Федерациясенең “Россия Федерациясендә белем бирү турында”гы Федераль Законы (№273, 29.12.2012);

-Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халык телләре турында” гы Законы (№1807-1, 12.03.2014);

-Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы (№68-ТРЗ 22.07.2013);

-Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесе “8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” нең 2018-2019нчы уку елына укыту планы;

-Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесе “8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” нең гомуми белем бирүнең төп укыту программасы.

Программа рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11 сыйныфлар. – Казан Татарстан китап нәшрияты, 2018. буенча атнага 1 сәгать исәбеннән елга 34 сәгать итеп төзелде.

Эш программасын тормышка ашыру өчен, түбәндәге укыту-методик комплекты файдаланылды.

1. Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11 сыйныфлар. – Казан Татарстан китап нәшрияты, 2018.
2. Ф.М. Мусин, З.Н. Хәбибуллина, Ә.М. Закирҗанов. Татар әдәбияты: рус телендә урта гомуми белем бирү мәкт. 11 нче сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия (татар балалары өчен). – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2012. – 311 б.

Уку фәненә характеристика

Билгеле булганча, укытуның максаты җәмгыять тарафыннан куелган социаль заказ белән билгеләнә. Татарстан Республикасының белем бирү системасына куйган төп бурычы – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт телендә һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы, билингваль шәхес формалаштыру.

Белем бирү өлкәсендә татар әдәбияты – эстетик төркемгә керүче предметларның берсе. Музыка, рәсем сәнгате белән янәшә сүз сәнгате – әдәбият укытыла. Ул дөньяны, тормышны, тарихны һәм бүгенгене, кешенең үз-үзен тотышын, психологиясен аңлауга ачкыч ролен үти, чөнки әдәбиятның төп өйрәнү-сурәтләү объекты – кеше, аның рухи дөньясы, тышкы дөнья, мохит һәм башка кешеләр белән мөнәсәбәтләре.

Максат:

-әдәби әсәрләргә таянып, иң яхшы сүз сәнгате үрнәкләрендә урын алган вакыйга-күренешләр аша татар халкы тормышы белән танышу, аның яшәешенә, төп проблемаларына, рухи дөньясына кагылышлы материалларны өйрәнү, әдәби әсәрләрне анализларга, бәяләргә өйрәтү.

Бурычлар:

-татар әдәбияты текстларын форма һәм эчтәлек берлегендә аңлап кабул итәргә өйрәтү;

-төп әдәби-тарихи мәгълүматлар һәм әдәби-теоретик төшенчәләр турында күзаллау булдыру;

-тиз үзгәрүчән заман шартларында файдалы җитештерүчән хезмәткә яраклы, үз-үзен танып белергә һәм һәрдаим камилләшергә әзер, гуманлы, рухи дөньясы бай шәхес тәрбияләү;

-гуманлылык карашлары, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, татар әдәбияты һәм мәдәни кыйммәтләренә кызыксыну һәм хөрмәт булдыру.

Укыту фәненең уку планында тоткан урыны.

Эш программасы МБОУ “8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” нең 2018/2019 нчы уку елына күрсәтелгән дәресләр санына яраклаштырылды. 11 нче сыйныфларның нигез программасында татар әдәбияты дәресләренә 34 сәгать вакыт каралган. Мәктәпнең уку планында да татар әдәбиятына атнага 1 сәгать бирелү сәбәпле, эш программасында елга 34 дәрес алынды. Шуңа күрә контроль һәм язма эшләргә, бәйләнешле сөйләм үстерүгә бирелгән сәгатьләр саны кыскартып алынды. Дәресләрдә, Интернет ресурслары белән эшләү кебек эш төрләрен дә киңрәк куллану, компьютер технологияләрен күбрәк кертү планлаштырыла.

Татар әдәбиятыннан программаның эчтәлеге

1917 елдан соңгы әдәбият(1 сәгать).

Яңа газета-журналлар, әдәби төркемнәр һәм агымнар (футуризм, имажинизм). Яңа тормыш ның поэтик бизәкләрен һәм сурәтләү телен эзләү. Әдәбияттагы төп темалар. Революция һәм шәхес, кеше, бәхет темасы. Әдәбиятта Ленин образы. Аны илаһилаштыр, идеаллаштыру. Әсәрләрдә Татарстан темасы. 20 нче елларда сатира, аның объектлары.

1920-1930 нчы еллар әдәбиятына күзәтү(3 сәгать).

Тормыш юлы, иҗады турында белешмә. "Казак кыззы" романы. Һади Такташ. "Мәхәббәт тәүбәсе" поэмасы. Гадел Кутуй. "Тапшырылмаган хатлар" повесте

40 – 50 нче еллар әдәбияты (4 сәгать).

Бөек Ватан сугышы алды һәм сугыш вакытында татар әдәбияты. Язучыларның сугышка корал һәм каләм белән катнашуы. Тылдагыларның фидакарь хезмәте һәм иҗаты. Шигърият, хикәянең активлашуы. Илленче елларда да сугыш темасының дәвам иттерелүе. Илленче еллар урталарында шәхес культының фаш ителүе. 1957 елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәрелү, аның әһәмияте . Муса Җәлил. "Тупчы анты" җыентыгы, "Моабит дәфтәрләре" җыентыгы. Фатих Кәрим. "Разведчик язмалары" повесте, "Сибәли дә сибәли" шигыре

1960-2000 еллар поэзиясе(9 сәгать).

Шигъри сүзнең эчке куәтен, җегәрен арттыруда уңышлар. Поэзиядә халык иҗатындагы, бөтендөнья әдәбияты һәм сәнгатендәге символикадан, шартлы алымнардан файдаланырга омтылышның артуы һәм җанлануы. Хәсән Туфан. Ә үткәнгә хатлар бармыйлар", "Кармәт истәлекләре", "Агыла да болыт агыла" шигырьләре.Сибгат Хәким. "Гел кряшка карый тәрәзәләрем", "Башка берни дә кирәкми" шигырьләре. Гамил Афзал. "Өф-өф итеп", "Кызыл балчык" промартелендә, "Мыек борам" сатирик шигырьләре. Ренат Харис. "Кеше кайчан матур?", "Хәл-әхвәл" шигырьләре. Рәдиф Гаташ. "Ирләр булыйк", "Укытучыма" шигырьләре. Равил Фәйзуллин. "Якты моң", "Яздан аерып булмый Тукайны" шигырьләре. Зөлфәт. "Тылсым", "Дүрт җыр" шигырьләре.

1960-2000 еллар прозасы(6 сәгать).

Татар прозаикларының тормыш турында объективрак фикер йөртергә омтылулары, тарихи әсәрләр тудырулары. Проза жанрында җәмгыять һәм шәхес мөнәсәбәте проблемасын яңача хәл иткән әсәрләр язылу.Тема төрлелеге.Гомәр Бәширов. "Җидегән чишмә" романы. Әмирхан Еники. "Әйтелмәгән васыять" хикәясе. Мәхмүт Хәсәнов. "Язгы аҗаган" романы. Нурихан Фәттах. "Әтил суы ака торур " романы. Мөхәммәт Мәһдиев. "Бәхиләшү" повесте.

1960-2000 еллар драматургиясе(2сәгать).

Бу еллардагы хәбәрдарлык һәм демократия күренешләренең уңай тәэсире нәтиҗәсендә татар драматургиясендәге җитди үзгәрешләр. Яңа иҗат көчләр килү. Тема төрлелеге. Туфан Миңнуллин. "Үзебез сайлаган язмыш" пьесасы.

Балалар әдәбияты(6 сәгать).

Татар балалар әдәбиятына күзәтү. Төп тема һәм проблемалар. Балалар әдәбиятының төрләре. Бүгенге татар балалар әдәбиятының төп иҗат көчләре. Җ. Тәрҗеманов, Х.Халиков, Җ. Дәрзаман, Шәүкәт Галиев, Роберт Мижнуллин әсәрләре.

"Туган тел (татар теле)" укыту предметының тематик планы

Программаның төп темалары/ бүлекләре	Сәгать саны	Агымдагы һәм арадаш контроль;	Контроль формасы
1917 елдан соңгы әдәбият	1		

1920-1930 нчы еллар әдәбиятына күзәтү	3		
40 – 50 нче еллар әдәбияты	4	Сочинение	Сочинение
1960-2000 еллар поэзиясе	9	Сочинение	Сочинение ;
1960-2000 еллар прозасы	8	Реферат	Реферат
1960-2000 еллар драматургиясе	2		
Балалар әдәбияты	5		
Кабатлау	2	Арадаш аттестация эше	Тест
Барлыгы	**34**		

Татар әдәбиятыннан календарь – тематик план

№	**Б/с.**	**Тема**	**С/с**	**Эчтәлек элементлары**	**Үткәрү вакыты**	
					План	**Факт**
		1. 1917 нче елдан соңгы әдәбият – 1 сәгать				
1	1.1	1917нче елдан соңгы әдәбият. Әдәбиятта көрәш темасының үзәккә куелуы.	1	Яңа газета-журналлар, әдәби төркемнәр һәм агымнар(футуризм, имажинизм). Яңа тормышның поэтик бизәкләрен һәм сурәтләү телен эзләү. Әдәбияттагы төп темалар. Революция һәм шәхес, кеше, бәхет темасы. Әдәбиятта Ленин образы. Аны илаһилаштыру, идеаллаштыру. Әсәрләрдә Татарстан темасы. 20 нче елларда сатира, аның объектлары.	5.09	
		2. 1920 - 1930 нчы еллар әдәбиятына күзәтү– 3 сәгать				
2	2.1	1920-1930 еллар әдәбияты.Төрле әдәби төркемнәр барлыкка килү. 1920-1930 нчы еллар әдәбиятына аеруча характерлы әсәрләр.	1	ТАССР төзелү, 21нче елгы ачлык, латин графикасына күчүвакыйгалары,аларның әдәби процесска йогынтысы. 30 нчы еллардагы репрессияләр корбаннары.	12.09	
3	2.2	Һади Такташ иҗаты. Һ. Такташның тормыш юлы һәм иҗади мирасы. “Мәхәббәт тәүбәсе”-	1	Шагыйрьнең тормышына, шәхесенә бәйле мәгълүматларны тулыландыру, истәлекләр белән баету һәм иҗатына күзәтү ясау. Шагыйрьнең әти-әнисе, үз гаиләсе, шәхесе турында сөйләү. Әсәрнең жанры. Сюжетына салынган вакыйгалар. Поэманың үзенчәлеге. Әсәрнең төп темасы, идеясы. Поэма турында төшенчә.	19.09	

		сюжет композициясе, әсәрнең темасы һәм төп идеясе.		Төп образларга характеристика.		
4	2.3	Гадел Кутуй. “Тапшырылмаган хатлар” повесте.	1	Г.Кутуйның шәхесе турында өстәмә материал бирү, аерым әсәрләре белән танышу. Әсәрнең яратып укылуының сәбәпләре. Вакыйгаларның хронологик тәртибе. Повестьның сюжет-композиция үзенчәлеге. Әсәрнең төп конфликты һәм проблемасы. Әсәрдәге гаилә һәм мәхәббәт мәсьәләләрен яктырту үзенчәлекләре.	26.09	
		3. 1940- 1950 нче еллар әдәбиятына күзәтү – 4 сәгать				
5	3.1	Бөек Ватан сугышы алды һәм сугыш чоры әдәбияты.	1	Бөек Ватан сугышы алды һәм сугыш вакытында татар әдәбияты. Язучыларның сугышка корал һәм каләм белән катнашуы. Тылдагыларның фидакарь хезмәте һәм иҗаты. Шигърият, хикәянең активлашуы. Илленче елларда да сугыш темасының дәвам иттерелүе. Илленче еллар урталарында шәхес культының фаш ителүе. 1957 елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәрелү, аның әһәмияте	3.10	
6	3.2	М. Җәлилнең сугышчан юлына, әсирлектәге тормышына, иҗатына күзәтү. “Моабит дәфтәрләре”.	1	Муса Җәлилнең тормыш юлы, фашизмга каршы көрәше турында түбән сыйныфларда өйрәнгәннәрне искә төшерү, яңа мәгълүматлар белән тулыландыру һәм фронт лирикасы белән таныштыру. “Моабит дәфтәрләре”нең тематик төрлелеге: Туган ил һәм ирек турында, үлем һәм яшәү фәлсәфәсе, фашизмга нәфрәт, мәхәббәт, хезмәт, балалар, җиңүгә ышаныч. Жанр ягыннан бүленеш: баллада, поэма, лирик шигырь, юмористик шигырь. Шигырьләрен анализлау.	17.10	
7	3.3	БСҮ.Сочинение. “Зинданнарны ватып чыккан җыр” (“Моабит дәфтәрләре”)	1	Кешенең Ватанны саклау сугышында җаваплылыгы тойгысы, аның төрле поэтик вариацияләре. Дошманга нәфрәтнең чагылышы. Сагыну, ярату, якыннарга хөрмәт һ.б. кешелек тойгыларының шигырьләрдә лаеклы урын алуы, аларның тәэсир көчен арттыруы.	24.10	
8	3.4	Ф.Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты. Тоткынлык чоры иҗаты.	1	Ф.Кәримнең фаҗигале тормыш юлы. Тоткынлык чоры иҗаты. Ф.Кәрим – солдат һәм шагыйрь. Сугыш чоры – әдип иҗатының иң югары ноктасына күтәрелгән чагы. Әсәрнең исеменә бәйле	7.11	

		“Разведчик язмалары” повестеның сюжет эчтәлеге.		үзенчәлеген билгеләү. Әсәрдә күтәрелгән мәсьәлә-проблемалар? Төп идеяны ачуда автор кулланган чаралар.		
		4. 1960-2000 еллар поэзиясе – 9 сәгать				
9	4.1	1960-2000 нче еллар әдәбияты	1	Җәмгыятьтәге кискен үзгәрешләрнең әдәбията чагылуы. Әсәрләрдә мөстәкыйльлеккә омтылу авазлары, милләтебез тарихына игътибарның артуы. Тарихи һәм табигатьне саклау темаларының артуы. Бүгенге әдәбиятта шәхес концепциясенең үзенчәлекләре.	14.11	
10	4.2	1960-2000 нче еллар поэзиясе.	1	Шигъри сүзнең эчке куәтен, җегәрен арттыруда уңышлар. Поэзиядә халык иҗатындагы, бөтендөнья әдәбияты һәм сәнгатендәге символикадан, шартлы алымнардан файдаланырга омтылышның артуы һәм җанлануы.	21.11	
11	4.3	Хәсән Туфан иҗаты. Х.Туфанның тормышы һәм иҗат баскычлары.	1	Шагыйрьнең тормыш юлы, шәхес буларак үзенчәлекле сыйфатлары. “Шигырьләрдә – шагыйрь язмышы” дигән гыйбарәнең Хәсән Туфанга туры килүе, “Ак чәчәк атар иде” дигән китаптан өзекләр белән танышу.	28.11	
12	4.4	Сибгат Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. С.Хәким иҗатында туган якның сурәтләнеше, нечкә лиризм.	1	Шагыйрьнең иҗат юлы белән таныштыру. Әсәрдә туган якның бирелеше, аларда нечкә лиризм.	5.12	
13	4.5	Гамил Афзал әсәрләре.	1	Гамил Авзал – татар поэзиясен үзенең нечкә юмор, үткен сатира ысулында язылган шигырьләре белән баетучы. Шагыйрьнең сатирик әсәрләре үзенчәлеген, иҗатының әһәмиятен ачу. Көлү объектлары һәм предметлары. Аларның халыкчан җирлекләре һәм халыкчан чаралар куллану.	12.12	
14	4.6	Бәйләнешле сөйләм үстерү.Сочинение “Тел озын – гомер кыска”	1	“Тел озын – гомер кыска” дигән темага әңгәмә кору. Гыйбарәнең мәгънәсен ачыклау, тормыштан мисаллар китерү.	19.12	
15	4.7	Зөлфәт шигырьләре: “Дүрт җыр”, “Баш очында”.	1	Зөлфәтнең тормыш юлы белән таныштыру. Иҗатының үзенчәлекле яклары. Шигырьләрендә үз тавышы, үз аһәңе булганлыгын төшендерү.	26.12	

		Ренат Харис иҗаты		Ренат Харисның тормыш юлы белән таныштыру, поэзиясе турында мәгълүмат бирү. Аның шигърияттә үз тасвирлау алымын, үзенчә язу стилен булдырырга омтылган шагыйрьләрнең берсе булуын аңлату.		
16	4.8	Рәдиф Гаташ – мәхәббәт җырчысы.	1	Кыскача тормыш юлы белән таныштыру, иҗатына күзәтү. Әсәрләрдә күтәрелгән төп мәсьәләләр, аларның сәнгатьчә эшләнеше. Шәрык классикасы традицияләрен татар поэзиясенә кайтаруы.	9.01	
17	4.9	Равил Фәйзуллин иҗаты.	1	Иҗаты турында белешмә. Әлеге шигырьләрендәге тирән уй, фәлсәфи олы фикернең бирелеше. Р.Фәйзуллинның туган иле, туган халкы турында уйланулары	16.01	
		5. 1960-2000 еллар прозасы — 8 сәгать				
18	5.1	1960-2000 нче еллар прозасы.	1	Татар прозаикларының тормыш турында объективрак фикер йөртергә омтылулары, тарихи әсәрләр тудырулары. Проза жанрында җәмгыять һәм шәхес мөнәсәбәте проблемасын яңача хәл иткән әсәрләр язылу.Тема төрлелеге.	23.01	
19	5.2.	Гомәр Бәшировның тормыш юлы һәм иҗаты. “Җидегән чишмә” романы.	1	Язучының тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу. Әсәрдә табигатьне саклауның әһәмиятен ачу,геройларны бәяләүдә табигатькә мөнәсәбәтнең роле. Образларга характеристика бирү, әсәрнең тел-стиле.	30.01	
20	5.3.	Ә.Еникинең тормышы һәм иҗат үзенчәлекләре. “Әйтелмәгән васыять” әсәренең сюжеты.	1	Тәрҗемәи хәле һәм иҗаты. Әдипнең 7 нче сыйныфта өйрәнгән әсәрләрен искә төшерү. Ә.Еникинең сугыш чоры хикәяләре. Алардагы психологик бизәкләр, гади кешенең эчке кичерешләрен дөрес һәм тәэсирле сурәтләү, детальләр төгәллеге. 50 нче, 60-80 нче еллар иҗаты. Авторның халык мирасына һәм аны үзләрендә йөртүчеләргә хәзерге мөнәсәбәтне яктырту үзенчәлекләре. Хикәянең сәнгатьчә эшләнеше, композициясендә үзенчәлекләр. Халыкның гореф-гадәте, туганлык җепләренең изгелеге, кеше күңеленә игътибарның җитмәве кебек сыйфатларның калку итеп куелуы. Болардан чыга торган төп фикер. Акъәби образы, аның халык намусын һәм рухи дөньясындагы сафлыкны гәүдәләндерүе. Ананың балаларына мөнәсәбәте, күңел җылылыгы, сизгерлеге, яңа йола-тәртипләрне аңларга омтылуы, үз	6.02	

				күңелендә электән урнашкан, канына сеңгән гадәтләрнең замана тудырган яңалыклар белән каршылыкка керүе. Кылган образы. Хикәядә Миңлебай карт әйткән соңгы сүзләрнең эчке мәгънәсе. Учак образы.		
21	5.4.	Мәхмүт Хәсәнов иҗаты. Язучының тормыш һәм иҗат юлына күзәтү ясау. “Язгы аҗаган” романы.	1	Язучының тормыш юлы һәм иҗат үзенчәлекләре. Аерым әсәрләренә күзәтү ясау.“Язгы аҗаган” романы: жанры, төзелеш үзенчәлекләре, андагы вакыйгалар. Әсәрдәге өч сюжет сызыгы: 1) «Яңа нефть ятмаларының перспективасын билгеләү 2) Газиның гыйбрәтле язмышы Газигә бәйле вакыйга-күренешләрне күзәтү, әлеге геройның һәм аның белән бәйле ешеләрнең эш-хәрәкәтләрен, характерларын билгеләү аша әсәр эчтәлеген ачу 3) Иргали, аның гаилә тормышы тасвирлану. Иргали тормышына, аның белән бәйле кешеләрнең эш-хәрәкәтләренә күзәтү ясап, аның характер сыйфатларын билгеләү, тормышта яшәү мәгънәсе, әлеге геройга автор салган йөкләмә	13.02	
22	5.5.	**ДТУ**. М.Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә.	1	Әсәрнең татар әдәбятында тоткан урыны,әсәр турында тәнкыйтьчеләр фикере	20.02	
23	5.6	Н.Фәттахның тормыш һәм иҗат юлы. “Итил суы ака торур” романының сюжет-композициясе һәм идея-проблематикасы	1	Сәнгатьле уку, образларга характеристика бирә белү	27.02	
24	5.7	**БСҮ.**Чит илләрдәге милләттәшләре без. Реферат язу.	1	Чит илдә яшәгән танылган татарлар турында материал туплау.Иҗади эшчәнлек.	6.03	
25	5.8	М. Мәһдиевнең тормышы һәм иҗаты**.** “Бәхилләшү” әсәренең идея-эстетик үзенчәлекләре.	1	Язучының тормыш юлы, шәхесе, әдәбиятка килүе. Иҗатының үзенчәлеге. Әсәрләре турында мәгълүмат бирү. Аларда сугыш алды, сугыш һәм сугыштан соңгы елларда татар авылы тормышын чагылдыру. Милли-этнографик материалга байлык, сәнгатьчә детальләрнең төгәл һәм мәгънәле булуы,	13.03	

				җанлы характерлар тудырудагы роле.		
		6. 1960-2000 еллар драматургиясе - 2 сәгать				
26	6.1	1960-2000 нче еллар драматургиясе.	1	Драма жанры буенча белемле булу.Драма жанрын дөрес уку, һәр бүлек буенча күзаллау булдыру.	20.03	
27	6.2	Туфан Миңнуллин иҗаты.. “Үзебез сайлаган язмыш” драмасы.	1	Драматургның тормыш һәм иҗат үзенчәлекләрен өйрәнү.Драмага килү юлы. Әсәрләренең тема һәм жанр ягыннан төрлелеге. Татар театр сәнгатен үстерүдә Т.Миңнуллин драматургиясенең роле	3.04	
		7. Балалар әдәбияты – 6 сәгать				
28	7.1	Балалар әдәбияты.	1	Татар балалар әдәбиятына күзәтү. Төп тема һәм проблемалар. Балалар әдәбиятының төрләре. Бүгенге татар балалар әдәбиятының төп иҗат көчләре.	10.04	
29	7.2	Җәвад Тәрҗеманов.	1	Җәвад Тәрҗеманов иҗатына күзәтү. Аның шигырьләрендә кеше һәм шәхес буларак формалашу процессындагы катлаулы мөнәсәбәтләрнең чагылышы.	17.04	
30	7.3	Шәүкәт Галиев.	1	Шәүкәт Галиев иҗатына күзәтү. Аның шигырьләрендә кеше һәм шәхес буларак формалашу процессындагы катлаулы мөнәсәбәтләрнең чагылышы.	24.04	
31	7.4.	Ш.Галиев шигырьләрендә шәхес формалашудагы катлаулы мөнәсәбәтләрнең чагылышы.	1	Аның балалар поэзиясен үстерүдәге эшчәнлеге. Шигырьләрдә темалар, образларның бирелеше.	8.05	
32	7.5.	Хәкимҗан Халиков. Җ.Дәрзаман. Роберт Миңнуллин	1	Хәкимҗан Халиков. Җ.Дәрзаман. Роберт Миңнуллин иҗатларына күзәтү. Әсәрдә образларының бирелеше. Экспозиция, төенләнеш, хәрәкәт үстерелеше, кульминация ноктасы, чишелеш	15.05	
33	7.6.	Арадаш аттестация эше	1	Ел буена алган белемнәрне тикшерү	22.05	
34	7.7	Хаталар өстендә эш. Ел буена үткәннәрне кабатлау	1	Әдәби процессның юлдашы буларак әдәби тәнкыйть. Соңгы еллар тәнкыйтендә актив эшләүче Мәхмүт Хәсәнов, Рафаэль Мостафин, Флүн Мусин, Азат Әхмәдуллин, Фоат Галимуллин, һ. б. Совет чорында татар әдәбияты узган юл: табышлар һәм югалтулар. Халыкның рухи һәм акыл хәзинәсен саклау һәм үстерүдә татар әдәбиятының роле	23.05	

Укучыларының белем дәрәҗәсенә таләпләр:

Укучы белергә тиеш:

1. Халык авыз иҗатының барлык жанрлары турында аңлатма бирә белергә.

2. Урта гасырдан алып, 1917 елга кадәр иҗат иткән әдипләрнең тормыш юлы, иҗаты турында аңлата һәм бәя бирә белергә.
3. Татар әдәбиятының төрле чорларына характеристика бирә белергә.
4. Әдәби төрләр, аларның жанрларына билгеләмә бирә белергә.
5. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген, төзелешен (тема, сюжет, композиция, идея, образлар системасы) анализлый белергә.
6. Әдәбият теориясе буенча материалларны тирәнтен белергә.
7. Сурәтләү чаралары һәм алымнары турында белергә.
8. Уңай герой, лирик герой төшенчәләрен аера белергә.

Укучы белә:
1. Укылган әсәр буенча әңгәмәдә катнаша, фикереңне белдерә ала.
2. Уку һәм сөйләм барышында орфоэпик нормаларны саклау, сөйләмдә җәенке, гади җөмләләрдән дөрес һәм урынлы файдалана.
3. Әсәр сюжетын сөйләп бирә, аның төзелеше буенча “хәтер картасы” төзи бел0.
4. Сурәтләү чараларыннан дөрес файдаланып, лирик һәм эпик, драма, лиро-эпик әсәрләрне анализлау күнекмәләренә ия була.
5. Әсәргә объектив бәя бирә белү, теләсә кайсы әсәрне анализлый, аңа рецензия яки аннотация яза белә.
6. Әдәби-тарихи процессның төп закончалыкларын, этапларын, чор әдәбиятына зур өлеш керткән әдипләр иҗатын белә.
-Мәктәп курсында өйрәнелгән әсәрләрне чорларның үсеш тәртибендә өзлексез барыш итеп күзаллый.
7. Әдәбият тарихы һәм теориясе буенча белемнәргә (тема, проблема, идея, пафос, образлар системасы, сюжет-композиция, телнең сәнгати сурәтләү чаралары, әдәби деталь) нигезләнеп, әдәби әсәрне анализлый һәм шәрехли.
8. Әсәрне чорга хас әдәби юнәлеш белән бәйлелектә тикшерә һәм аңлата белә.
9. Классик әдипләребезнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын белә.
10. Әдәбият теориясенә караган иң әһәмиятле төшенчәләрне, аларның билгеләмәләрен белә (әдәби процесс, иҗат методы, сәнгатьчә алымнар-чаралар, анализ төрләре, язучының стиле, әдәбият һәм чор, шәхес һәм җәмгыять бәйләнешләре).
11. Татар әдәбиятында традицияләр һәм яңару процессы, жанрлар үсеше турында гомуми күзаллый ала.

Уку- укыту методик комплекты:
1. Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11 сыйныфлар. – Казан Татарстан китап нәшрияты, 2018.
2. Ф.М. Мусин, З.Н. Хәбибуллина, Ә.М. Закирҗанов. Татар әдәбияты: рус телендә урта гомуми белем бирү мәкт. 11 нче сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия (татар балалары өчен). – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2012. – 311 б.

Әдәбият исемлеге:
Укытучы өчен:

1. Д. Ф. Заһидуллина. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы: Метод. кулланма. – Казан: Мәгариф, 2010. – 335 б.
2. 2. Ф.М. Хатипов. Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. Тулыландырылган икенче басма.-Казан: Раннур, 2012.-352б.
3. 3. Д.Ф. Заһидулла, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев. Татар әдәбияты: Теория. Тарих.-Казан: Мәгариф, 2014.-247б.
4. 4. А.Г. Яхин. Әдәбият дәресләре: Укытучылар, югары уку йортлары студентлары һәм укучылар өчен методик кулланма.-Казан: Мәгариф, 2013.-159б.

5. Д.Ф.Заһидулла, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев. Татар әдәбияты: Теория. Тарих.-Казан: Мәгариф, 2014.-247б.

Укучылар өчен:

1. А. Гыйләҗетдинова. Татар телен өйрәнүчеләр өчен текстлар. – Казан: “Яңалиф” нәшрияты, 2014. – 40 б.
2. 3. Р. Рахман. Татар телендә 100 сочинение: Мәктәп укучысына ярдәмлек. – Казан: “Раннур” нәшрияты, 2011. – 148 б.
3. 4. Каеннар сары иде...: Ватан сугышы чоры әдәбияты.-Казан: Мәгариф, 2014.-399б.